


Сəламəтлек – кеше очен ин моһим, ин кирəкле нəрсə. Ана игътибарлы булып, даими тостə медицина кvзəтv vтv зарур. Табиблар һəрвакыт халык белəн. Бvгенге кондə алар район сулышын тоеп, чордашлары белəн бергə заман vзгəрешлəрен кvнеллəре аша уздырып, һəр вакыйгага vз карашларын белдереп, жəмгыять тормышынын уртасында кайнап яшилəр. Торбеево районы - аларнын язмышы. Халыкка һəм хезмəткə тугрылык кvрсəтv - Айсылу Мəхмvт кызы Семочкинанын, Зульфия Шəмил кызы Дулатованын, Наилə Шəмил кызы Якунинанын яшəv асылы.Əнə шулай яраткан хезмəтеннəн лəззəт алып эшлилəр чын табиб булып туган кешелəр.      Табиблыкка гомерлəрен багышлаганнар тvбəндəге сыйфатларга хас. Алар авыруларга кvбрəк игътибар бирəлəр, аралашалар. Табиб эше язу - карта тутыруда гына тvгел (электроны булса да), авыруларга изге монəсəбəттə чагыла. Доктор очен очəр-дvртəр кон бəйрəм, ял коннəре булмый: чирле кешенен хəлен даими белеп торырга кирəк дип саныйлар.Органнарнын vзара бəйлəнешен анлап, чирнен тулы картинасын кvзаллый белəлəр, чонки авырткан органны гына дəвалау да дорес тvгел дип саныйлар. Шунда гына дəвалау курсы тиешле нəтижə бирə.

Айсылу Мəхмvт кызы Семочкина, «Торбеевская центральная районная больница»сында житəкче вазыйфасын vти.

Сvзебез больница белəн танышудан башланды. Торбеево ЦРБ стационары карамагында 135 урын, анын 40 кондезге дəвалану урыны, поликлиниканын бер сменасында гына 450дəн артык кешене кабул итə, 27 фельдшер-акушер пункты, тиз ярдəм бvлеге һəм башка хезмəтлəр керə. Анда 62 табиб һəм 199 шəфкать туташы белəн башка юнəлеш эшчелəре бар. Бvген информатизация проекты буенгча Торбеево районы vзəк больницасы (ЦРБ) кирəкле  компьютер техникасы белəн тəэмин ителгəн, локаль-санау челтəре эшли, медицина информацион системасы эшкə кертелгəн; болар барысы да пациентларнын персональ исəпне һəм бердəм электрон карталарны алып барырга ярдəм итə. Тагы Торбеево больницасы дvрт федераль программада катнаша: йорəк-кан юллары, онкологик авыруларга ярдəм итv, ДТПга юлыкканнарга ярдəм кvрсəтv һəм сəламəтлекне саклауны модернизациялəv. «Кан əйлəнеше авыруларына беренчел ярдəмне камиллəштерv - совершенствование»  проектын тормышка ашыру кискен

коронар синдромы белән авыруларнын vлveн 6,9% тан 5,7%  киметергә ярдәм итте. Авыруларны вакытында ачыклап, кичекмәстән ярдәм итv буенча диспансерлаштыру программасы унышлы эшләп килә, ашыгыч ярдәм kvрсәтv оештырылган, бу исә хезмәтебезнен нәтижәсен тагын да яхшыртырга ярдәм итә. «Земский доктор» программасы буенча докторларыбыз сафы артты, дип тә хәбәрләде житәкче.
- Даими рәвештә медицина тикшеренve vтv авыруларны, бvгенге кондә шактый кин таралган йорәк-кан тамырлары (инфаркт, инсульт, югары кан басымы), яман шеш авыруларын, шикәр диабеты, хроник vпкә һәм бронх авыруларын булдырмый калу яки



беренчел стадиясендә тиешле дәвалау билгеләv очен әһәмиятле. Максатларнын берсен kvз алдында тотып, 2001нче елда районара онкология кабинеты ачылган иде; бvген унышлы эшли, - ди баш табиб Айсылу Мәхмvтевна. – Программа буенча кон таләп иткән жиһаз урнаштыру белгечләребезгә рак алды һәм онкология авыруларын беренчел стадиядә билгеләргә ярдәм итә; диагностик kvрсәткечләр 12,4% vсте. Бу саннар артында йозләгән кеше гомере. Тырыш онколог олкәсе белгечебез Зульфия Шәмил кызы Дулатова турында пациентлары гел яхшы сvзләр генә ишеттерә: vз профессиясендә чын белгеч, хезмәтенә ихлас бирелгән, тәжрибәле, намуслы, игелекле табибә. Бvген ул дикрет ялында. Әле генә оченче бала тудырды. Анын очен шатландык.
Тыйнак, vзе турында kvп сойләргә яратмаган Айсылу Мәхмvт кызы тумышы белән Атюрьево районы Большой Шуструй-Кыштыру авылыннан. Әтисе - Мәхмvт Ибәдулла улы Ингильдеев, гомере буе тырышып туган авылындагы «Восход» колхозында хезмәт итә, ә әнисе - Ракия Абдрахман кызы, озак еллар Кыштыру авылы администрациясен житәкли. Тату, булдыклы гаиләдә белемле балалар тәрбиялиләр алар. Бvген дә балаларына, оныкларына, булдыра алган кадәр, булышалар; олы яшьтә булуларына карамастан, тавыклар белән сарыклар асрыйлар. Балалары да хормәтли аларны;  аларга ярдәм итәләр. Мәсәлән, жәйге печән чабуларын гына алыйк. Бу чорны Айсылу ханым бигърәк ярата. Гаиләсе белән печән чабарга, жыярга булыша. Ә туган Кыштыру авылы иген-кырлары, андагы хуш исле жиләкләре, бер жирдә дә табылмаган матур чәчәкләре житәкченен kvнелендә рәхәтлек хисе тудыра. Басудан арып кергәч, әнисенен бик тә тәмле бәлешләре (пальчики оближешь, ди) һәм катламалары бел

